Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

11 май 2018 ел № 238

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә" 145 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәтләр турында» №25-ФЗ Федераль Законга, 2017 елның 1 июлендәге "Россия Федерациясендә аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" №132-ФЗ, 2013 елның 25 июнендәге "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы" № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокурорының 2018 елның 27 февралендәге 143 номерлы күрсәтмәсен карап

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә" 145 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы №166, 2017 елның 5 маендагы №178, 2017 елның 31 маендагы №184, 2017 елның 25 сентябрендәге №196 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар кушымтасындагы 9 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 9.18 пункты белән тулыландырырга:

"Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү турында мәгълүматлар җирле үзидарә органнары тарафыннан "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законның 15 маддәсендә каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгәннәр реестрына кертелә.

2. Район башкарма комитеты хокук идарәсенә (Шәйхулова Ф.Х.) әлеге карарны "Әлмәт хәбәрләре" газетасында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында" һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының закон, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (И.Р. Баһманов) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин